**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 12 декабрендәге 5153 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 10 октябрендәге 3434 номерлы**
**«Махсус хәрби операциядә катнашучы**
**Россия Федерациясе гражданнары балаларына**
**күрсәтелә торган социаль ярдәм чаралары турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнары балаларына социаль ярдәм күрсәтү максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 10 октябрендәге 3434 номерлы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 13 мартындагы 740 номерлы, 2023 елның 19 маендагы 1423 номерлы, 2023 елның 15 ноябрендәге 3511 номерлы, 2023 елның 4 декабрендәге 3833 номерлы, 2024 елның 6 июнендәге 2328 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 1 пунктны түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«1. Казан шәһәре территориясеннән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнары, махсус хәрби операциядә катнашып, һәлак (вафат) булган Россия Федерациясе гражданнары, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче затлар һәм хәрби хезмәткәрләр, Татарстан Республикасында төзелгән “Алга”, “Тимер” һәм “Батыр” батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле рәвештә үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре балаларына, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнары гаиләләрендә тәрбияләнүче, ирнең (хатынның) беренче (башка) никахтан туган балаларына, 2022 елның

10 октябреннән алып 2025 елның 31 декабренә кадәр Казан шәһәренең шәһәр пассажир транспортында исемле электрон юл билетлары (транспорт картасы) (алга таба – электрон юл билеты) буенча бушлай йөрү мөмкинлеге биреп, социаль ярдәм чараларын билгеләргә»;

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**